**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4949**
**27.09.2019**

2019-2020 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю урыннары турында

Карны үз вакытында чыгаруны тәэмин итү һәм кар өюне тәртипкә салу максатларында, Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 190 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. 2019-2020 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

- Карьерная урамы буенча мәйданы 10 га булган территориядә (КСМ карьеры);
- Төзелеш тыкрыгы буйлап мәйданы 2,5 га булган территориядә;
- Техническая урамы буенча мәйданы 22,75 га булган территориядә (кадастр номеры 16:52:100101:117);
- Техническая урамы буенча мәйданы 2,62 га булган территориядә (кадастр номеры 16:52:100101:8);
- Казан проспекты һәм Иске Сарман урамы кисешкән урын (16:52:080504).


2. 2019-2020 елларның кышкы чорына, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вакытлыча кар өю урыннары урнашуын кушымтада каралганча расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Приложение к постановлению
Исполнительного комитета
от "___"_______________20____г. №________

# Схема расположения мест временного складирования снега в зимний период 2019-2020 гг.



Условные обозначения:

1 — ул. Карьерная (карьер КСМ) площадью 10 га

2 — вдоль проезда Тозелеш площадью 2,5 га

3 — по ул. Техничесская (з/у 16:52:100101:117), площадью 22,75 га

4 — по ул. Техничесская (з/у 16:52:100101:8), площадью 2,65га

5 — пересечение Кказанского пр-та с ул. Старосармановская (напротив 20 комплекса, з/у 16:52:080504

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева